КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 13 июль г.Казань № 578

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 2 ноябрь, 837 нче карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 2 ноябрь, 837 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 май, 380 нче, 2015 ел, 12 ноябрь, 849 нчы; 2016 ел, 4 февраль, 66 нчы; 2016 ел, 22 июль, 499 нчы; 2017 ел, 15 май, 285 нче; 2018 ел, 2 апрель, 201 нче; 2018 ел, 29 август, 731 нче; 2019 ел, 16 апрель, 296 нчы; 2019 ел, 20 август, 690 нчы; 2020 ел, 27 апрель, 336 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекнең кырык икенче абзацында «(хәзерге вакытта гамәлдә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

«2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгы» ярдәмче программасының II бүлегендә:

утыз сигезенче абзацта «җайланмасы» сүзен «җайланмалары» сүзенә алыштырырга, «янгын сүндерү» сүзләре алдына «автомат» сүзен өстәргә;

алтмышынчы абзацта «министрлыклар, ведомстволар, оешмалар һәм торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләренең» сүзләрен «башкарма хакимият органнары, оешмаларның» сүзләренә алыштырырга;

алтмыш беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Оешмалар хезмәткәрләрен янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне оештыруга карата таләпләр Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының «Оешмалар хезмәткәрләрен янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү» янгын куркынычсызлыгы нормаларын раслау турында» 2007 елның 12 декабрендәге 645 номерлы боерыгы белән билгеләнгән.»;

йөз егерме беренче абзацта «(нигез – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының «Янгын сүндерү машиналары өчен сыек ягулыкны тоту нормалары турында» 1993 елның 20 декабрендәге 54 номерлы боерыгы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

«2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычын киметү һәм нәтиҗәләрен йомшарту» ярдәмче программасында:

I бүлекнең икенче абзацында «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 11 мартындагы б-390 номерлы боерыгы белән расланган үз вәкаләтләренең бер өлешен бер-берсенә тапшыру турында төзелгән килешү нигезендә», «Килешүнең үтәлешенә ясалган анализ күрсәтүенчә, ул республикага да, федераль үзәккә дә аларга беркетелгән вәкаләтләрне тормышка ашыру кысаларында чараларны, бер-берсен тулыландырып, әмма кабатламыйча, тулы күләмдә гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләре килешү нигезендә Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең оператив идарәсендә тора һәм алар, бергәләп, гадәттән тыш хәлләрдән саклау, гражданнар оборонасы, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында иминлекне тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы вәкаләтләрен башкара» сүзләрен төшереп калдырырга;

II бүлектә:

унтугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасында Россия Федерациясе

Хөкүмәтенең 2019 елның 10 октябрендәге б-2380 номерлы боерыгы белән расланган халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм мондый мәгълүмат белән алмашу, муниципальара һәм төбәк характерындагы гадәттән тыш хәлләр булганда һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләрне оештыру һәм үткәрү, Янгынга каршы дәүләт хезмәте көчләре белән янгыннар сүндерүне оештыру буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турындагы килешүгә кул куелды.»;

егерме өченче абзацта «131» саннарын «131-ФЗ» сүзләренә алыштырырга;

«2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» ярдәмче программасына теркәлгән кушымтадагы искәрмәнең беренче абзацында «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 11 мартындагы б-390 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм алар салган зыяннарны бетерү, муниципальара һәм төбәк характерындагы гадәттән тыш хәлләр булганда һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләрне оештыру һәм үткәрү, Янгынга каршы дәүләт хезмәте көчләре белән янгыннарны сүндерүне оештыру, муниципальара һәм төбәк дәрәҗәсендә гражданнар оборонасы чараларын гамәлгә ашыруны, Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләрне эзләү һәм коткаруны гамәлгә ашыруны оештыру буенча вәкаләтләрнең бер өлешен бер-берсенә тапшыру турындагы килешү» сүзләрен «Вәкаләтләр» сүзенә алыштырырга;

«2016 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексын төзү һәм үстерү» ярдәмче программасында:

Ярдәмче программа паспортының «Дәүләт заказчылары» юлының беренче абзацында «Мәгълүматлаштыру» сүзен «Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре» сүзләренә алыштырырга;

I бүлектә:

егерме бишенче абзацта «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә «112» телефон номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү системасы турында» 2010 елның 22 мартындагы 166 номерлы» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендә «112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү системасын үстерү турында» 2018 елның 20 февралендәге 103 номерлы» сүзләренә алыштырырга;

егерме тугызынчы абзацта өченче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ашыгыч чакырулар хезмәте – 112» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан «112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә муниципаль берәмлекләрнең ашыгыч оператив, башка чаралар күрү хезмәтләренең һәм бердәм кизү-диспетчерлык хезмәтләренең үзара мәгълүмати хезмәттәшлеге буенча гомуми регламент Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү буенча дәүләт

хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2019 ел, 28 август, 731 нче карары белән расланды.»;

II бүлектә:

«Татарстан Республикасында «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексын төзү һәм кулланышка кертү өчен норматив хокукый һәм регламент базасын әзерләү» бурычы чаралары» бүлекчәсенең 5 нче пунктында:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 өлеше нигезендә куркынычлылыгы I һәм II класслы булган куркыныч җитештерү объектларын, аеруча радиация куркынычы һәм атом-төш куркынычы булган җитештерүләрне һәм һәлакәтләр салган зыяннары аларның территориясеннән читтә зарарлаучы факторларның йогынтысы зоналарында яшәүче яки хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы халыкның тормышына һәм сәламәтлегенә зыян китерә торган объектларны, гадәттән тыш югары дәрәҗәдә куркынычлы гидротехник корылмаларны һәм югары дәрәҗәдә куркынычлы гидротехник корылмаларны эксплуатацияләүче оешмалар локаль хәбәр итү системаларын булдыра һәм аларның әзер булуын тәэмин итә.»;

унберенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

«Имин шәһәр» аппарат-программа комплексында җирле үзидарә органнарының, хокук саклау органнарының, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр хезмәтләренең, шәһәр инфраструктурасы хезмәтләренең килештерелгән гамәлләрен тәэмин итү» бурычы чаралары» бүлекчәсенең 1 нче пунктында:

икенче абзацта «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә «112» телефон номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү системасы турында» 2010 елның 22 мартындагы 166 номерлы» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендә «112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү системасын үстерү турында» 2018 елның 20 февралендәге 103 номерлы» сүзләренә алыштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2019 ел, 28 август, 731 нче карары белән «Ашыгыч чакырулар хезмәте – 112» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан «112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә муниципаль берәмлекләрнең ашыгыч оператив, башка чаралар күрү хезмәтләренең һәм бердәм кизү-диспетчерлык хезмәтләренең үзара мәгълүмати хезмәттәшлеге буенча гомуми регламент расланды.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин